# Оялчан балалар.

Оялчанлык – ул олыларга һәм балаларга , күп кешеләргә хас үзенчәлек. Оялчанлык аралашуны катландыручы - иң таралган сәбәпләрнең берсе. Аның нәтиҗәләре күңелсез булырга мөмкин.

1.**Оялчанлык -** кеше белән аралашырга, яңа кешеләр белән очрашырга ирек, аралашудан канәгатьлек бирми.

2.Үз сүзен әйтергә, үзенең хокукын якларга комачаулый.

3. Ул ачык уй-фикерләргә, нәтиҗәле аралашуга комачаулый.

4.Оялчанлык депрессия, борчулык, ялгызлык белән бергә бара.

Оялчан булу-димәк, кешеләрдән курку, ә куркыныч кешеләрдән бигрәк тә. Кайдан барлыкка килә? Хәзерге көндә, психология фәне оялчанлыкны – ул кеше белән аралашкан чагында барлыкка килгән курку хисе реакциясенең нәтиҗәсе дип атый, ул беренче аралашу тәҗрибәсеннән барлыкка килә һәм ныгып кала. Оялчан бала ничек аралашырга кирәген белә, тик билгеле бер эчке сәбәпләр аркасында аралашмый.Ул үзенең тотышының адекват түгеллеген сизә, үзенең гамәлләре өчен эзлесез борчыла. Аралашу өчен кирәк булган көчнең балада булмавы үз-үзен түбәнсетүгә китерә.

**Ничек итеп андый балаларга оялчанлыкны бетерегә ярдәм итәргә?**

-Даими рәвештә балада коюлык, үз көченә ныклы ышаныч тәрбияләргә,

-андый бала өчен артык борчылмаска, ә аңа билгеле бер дәрәҗәдә мөстәкыльлек биререгә;

-оялчан балага аралашу өчен төрле шартлар тудырырга; аңа башка кеше белән мөгаләмәгә кереп төрле йомышлар, эшләр тапшырырга кирәк;

-баланы яңа шартларга, үзгәрешләргә тыныч карарга, баланың таныш кешеләр санын арттырырга, еш дуслар белән аралашып торырга , саф һавада йөрү маршрутларын үзгәртергә тәгъдим ителә;

-Башлангыч чорда бәйрәмнәр вакытында оялчан балалар эти-әниләре белән бергә чыгышлар ясаса, соңыннан үзләре мөстәкыйль чыгып сөйләгән балаларның күңелен күтәреп җибәрергә, мактарга , шулай әкеренләп кеше янында чыгыш ясау күнекмәсе булдырырга, чит кешедән куркуны бетерергә.